СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ**
**29 декабрь, 2025 ел**

**КАРАР**
**№ 36**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә һәлак (вафат) булган махсус хәрби операциядә катнашучыларны җирләүне оештыру турында**

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Ватанны саклаучыларның, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучыларның истәлеген мәңгеләштерү буенча РФ Хөкүмәте тарафыннан 2025 елның 30 августындагы МД-П4-32257 номерлы белән расланган бердәм тәкъдимнәр нигезендә, хәрби бурычын үтәгәндә батырлык һәм каһарманлык күрсәткән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучыларның истәлеген мәңгеләштерү, шулай ук аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан зиратларда һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучыларны җирләүне оештыру функцияләрен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенә күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны түләү өлешендә йөкләргә.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан зиратларда һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучыларны күмүне җайга сала торган тиешле хокукый актлар эшләүне тәкъдим итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә җирле бюджет акчалары (өстәмә рәвештә алынган керемнәр) исәбеннән финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов